ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.18а, д.Малые Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 18а йорт, Рече Урыссу авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 5** **16 октябрь 2020 ел**

«Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Хөррият торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1 һәм 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 9 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы К А Р А Р И Т Т Е:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Хөррият торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2020 елның 30 октябренә 14.00 сәгатьтә «Дубравушка» муниципаль бюджет учреждениясенең актлар залында гражданнар җыенын билгеләргә.

Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2021 елда үзара салым кертүгә Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Хөррият торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Зират коймаларын урнаштыру (материаллар алу).

«ӘЙЕ» «ЮК».

2. Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

«Ташкичү авыл җирлеге»
муниципаль берәмлек башлыгы Р.К.Вәлиев